КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 21 март г.Казань № 315

2023 елда муниципаль район чикләрендә җирлекләр арасында җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары буенча пассажирлар йөртүне оештыру максатларында Татарстан Республикасы муниципаль районнары бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2023 елда муниципаль район чикләрендә җирлекләр арасында җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары буенча пассажирлар йөртүне оештыру максатларында Татарстан Республикасы муниципаль районнары бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен расларга.
2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 21 март, 315 нче
карары белән расланды

**2023 елда муниципаль район чикләрендә җирлекләр арасында җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары буенча пассажирлар йөртүне оештыру максатларында Татарстан Республикасы муниципаль районнары бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе**

1. Бу Тәртип 2023 елда муниципаль район чикләрендә җирлекләр арасында җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары буенча пассажирлар йөртүне оештыру максатларында Татарстан Республикасы муниципаль районнары бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар (алга таба – шул ук эзлеклелектә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары, муниципаль район, башка бюджетара трансфертлар) бирү механизмын, максатларын һәм шартларын билгели.

2. Башка бюджетара трансфертлар бу Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен акча белән баш эш итүче буларак Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына (алга таба – Министрлык) билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары һәм бюджет ассигнованиеләре чикләрендә бирелә.

3. Муниципаль район бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары:

даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль контрактлар булу;

муниципаль районның үтәү өчен башка бюджетара трансферт бирелә торган чыгым йөкләмәсен билгели торган муниципаль хокукый акт булу;

муниципаль район бюджетында (муниципаль район бюджетының җыелма бюджет исемлегендә) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары буенча пассажирлар йөртүне оештыру өлкәсендә чыгым йөкләмәләрен үтәү өчен аларны үтәргә кирәкле күләмдә (Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар күләмен кертеп) бюджет ассигнованиеләре булу;

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Министрлык һәм муниципаль район арасында расланган бертип форма буенча башка бюджетара трансфертлар бирү турында килешү (алга таба – килешү) төзү, анда даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары буенча пассажирлар йөртүне оештыру өлкәсендә чыгым йөкләмәләрен үтәү буенча муниципаль

районның йөкләмәләре һәм килешүдә билгеләнгән йөкләмәләрне үтәмәгән өчен җаваплылык карала.

4. Муниципаль районнар арасында башка бюджетара трансфертларның бүленеше Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының хокукый акты белән раслана.

5. Башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсе – Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары реестрына кертелгән, Татарстан Республикасы тиешле муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырылган даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары буенча көн саен даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның һәр муниципаль маршруты буенча кимендә ике круг рейс пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру.

6. Башка бюджетара трансфертлар алу өчен муниципаль район Министрлыкка, башка бюджетара трансфертларга ихтыяҗның финанс-икътисадый нигезләвен теркәп, башка бюджетара трансфертлар бирү турында ирекле формада заявка (алга таба – заявка) һәм түбәндәге документларны тапшыра:

агымдагы финанс елына муниципаль район бюджеты турында муниципаль районның вәкиллекле органы карарыннан (муниципаль район бюджетының җыелма бюджет исемлегенннән) муниципаль район бюджетында даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары буенча пассажирлар йөртүне оештыру өлкәсендә чыгым йөкләмәләрен үтәү өчен аларны үтәргә кирәкле күләмдә (Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар күләмен кертеп) бюджет ассигнованиеләре булуны раслый торган өземтә;

бу Тәртипнең 3 пунктындагы икенче абзацында күрсәтелгән контрактның күчермәсен;

бу Тәртипнең 3 пунктындагы өченче абзацында күрсәтелгән, муниципаль районның үтәү өчен башка бюджетара трансферт бирелә торган чыгым йөкләмәсен билгели торган муниципаль хокукый актның күчермәсен.

7. Министрлык:

заявканы һәм бу Тәртипнең 6 пунктында каралган документларны алар кергән көннән алып бер эш көне эчендә терки;

заявка теркәлгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә бу Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән документларны карап тикшерә һәм башка бюджетара трансфертлар бирү турында яки башка бюджетара трансфертлар бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

8. Башка бюджетара трансфертлар бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

муниципаль берәмлек тарафыннан бу Тәртипнең 3 пунктындагы икенче – дүртенче абзацларында күрсәтелгән башка бюджетара трансфертлар бирү шартларын үтәмәү;

заявканы һәм бу Тәртипнең 6 пунктында каралган документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

заявкадагы һәм бу Тәртипнең 6 пунктында каралган документлардагы мәгълүмат дөрес булмау.

9. Башка бюджетара трансфертлар бирүдән баш тарту сәбәпләре күрсәтелгән башка бюджетара трансфертлар бирүдән баш тарту турындагы хәбәрнамә Министрлык тарафыннан заявка теркәлгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә муниципаль районга җибәрелә.

10. Муниципаль район бу Тәртиптә билгеләнгән таләпләрне үтәү шарты белән башка бюджетара трансфертлар бирүдән баш тарту турында хәбәрнамә алынган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә заявканы һәм бу Тәртипнең 6 пунктында каралган документларны яңадан бирергә хокуклы.

11. Башка бюджетара трансфертлар Министрлык тарафыннан башка бюджетара трансфертлар бирү турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә Министрлык һәм муниципаль район арасында төзелә торган, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган бертип форма буенча башка бюджетара трансфертлар бирү турында килешү нигезендә бирелә.

12. Килешүдә түбәндәгеләр карала:

башка бюджетара трансфертларның максатчан билгеләнеше;

бирелә торган башка бюджетара трансфертлар күләме;

башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәсенең күрсәткече;

башка бюджетара трансфертларны күчерү тәртибе һәм сроклары;

башка бюджетара трансферт бирү нәтиҗәсенең күрсәткеченә ирешү һәм аңа ирешү максатларында кабул ителгән йөкләмәләр турында хисап бирү сроклары һәм формалары;

башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсенең билгеләнгән күрсәткеченә ирешмәү нәтиҗәләре;

муниципаль районның вәкаләтле җирле үзидарә органы тарафыннан килешүдә каралган башка бюджетара трансфертлардан файдалану йөкләмәләре үтәлүен контрольдә тотуны гамәлгә ашыру тәртибе;

якларның килешү шартларын бозган өчен җаваплылыгы.

13. Башка бюджетара трансфертлар Министрлык тарафыннан килешү төзелгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә муниципаль районның финанс органына ачылган муниципаль район бюджетының бердәм счетына күчерелә.

14. Муниципаль район 2024 елның 1 февраленә кадәр Министрлыкка килешүдә каралган тәртип һәм форма нигезендә башка бюджетара трансферт бирү нәтиҗәсенең күрсәткеченә ирешү һәм аңа ирешү максатларында кабул ителгән йөкләмәләр турында хисап тапшыра.

15. Башка бюджетара трансфертлардан файдалануның нәтиҗәлелеген бәяләү Министрлык тарафыннан килешүдә билгеләнгән башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәләренең күрсәткечләрен 2023 ел йомгаклары буенча фактта ирешелгән башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәләренең күрсәткечләре белән чагыштырып карау юлы белән гамәлгә ашырыла.

16. Муниципаль район тапшырыла торган хисап белешмәләре дөрес булмаган һәм башка бюджетара трансфертлардан максатчан файдаланмаган өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап бирә.

17. 2024 елның 1 гыйнвары хәленә карата файдаланылмаган башка бюджетара трансфертлар 2024 елның беренче 15 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

Башка бюджетара трансфертларның файдаланылмый калган өлеше Татарстан Республикасы бюджеты кеременә күчерелмәгән очракта, әлеге акча, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләрне үтәп, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә түләтелергә тиеш.

18. Әгәр 2024 елның 1 гыйнвары хәленә карата муниципаль район тарафыннан килешүдә каралган йөкләмәләр бозылган булса, башка бюджетара трансфертлар 2024 елның 1 мартына кадәр муниципаль берәмлек бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына тулы күләмдә кире кайтарылырга тиеш.

19. Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары бу Тәртип һәм килешү белән билгеләнгән башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыра.

20. Башка бюджетара трансфертлардан максатчан файдаланылмаган һәм (яки) муниципаль район тарафыннан аларны бирү шартлары бозылган, шул исәптән муниципаль район тарафыннан бу Тәртипнең 18 пункты нигезендә акча Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылмаган очракта, аңа карата Россия Федерациясенең бюджет законнарында каралган мәҗбүр итүнең бюджет чаралары кулланыла.

21. Бу Тәртип нигезендә бирелгән башка бюджетара трансфертлардан максатчан һәм нәтиҗәле файдалануны контрольдә тоту Россия Федерациясе законнары нигезендә Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.